КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 апрель г.Казань № 499

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 19 февраль, 88 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1205 нче; 2022 ел, 14 февраль, 128 нче; 2022 ел, 1 август, 744 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1499 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен;

Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру кысаларында яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентын.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренең хатын-кызлар консультация-

ләрендә (кабинетларында) йөклелек чорында диспансер күзәтүендә торучы хатын-кызларга Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру кысаларында яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү хокукы турында мәгълүмат бирү хакында норматив документ эшләргә.»;

әлеге карар белән расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче яңа туган балалары булган гаиләләргә, Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләрен тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарының 1 пунктында күрсәтелгән яңа туган балалы гаиләләр категорияләрен балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) Татарстан Республикасы

бюджетыннан субсидия (алга таба – яңа туган балалы гаиләләр, бүләк комплектлары, субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.»;

2.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1еннән иртәрәк булмаган датага карата түбәндәге коммерция карамаган оешмалар сайлап алуда катнашучы була алмый:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тора. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.3 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енче көне хәленә карата Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым органы тарафыннан бирелгән коммерциягә карамаган оешманың салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмавын раслый торган белешмә кәгазен;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган белешмә кәгазен;»;

2.10 пунктның тугызынчы абзацында «2023 елда – 4 365 берәмлек» сүзләрен «2023 елда – 3 828 берәмлек» сүзләренә алмаштырырга;

3.12 пунктның беренче абзацында «2023 елда – 4 365 берәмлек» сүзләрен «2023 елда – 3 828 берәмлек» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта»;

заявка формасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә сайлап алуда катнашуга заявка»;

таблицадан соң беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заявкада бирелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес дип һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарының 1 пунктында күрсәтелгән яңа туган балалы гаиләләр категорияләрен балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру бәйле социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә сайлап алуны оештыру һәм үткәрү максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан әлеге заявка турында һәм сайлап алуда катнашуга бәйле заявка бирүче турында мәгълүматны һәм тиешле сайлап алуга бәйле заявка бирүче турында башка мәгълүматны Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгаруга (урнаштыруга) үземнең ризалыгымны бирәм дип белдерәм.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре

арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче яңа туган балалары булган гаиләләргә, Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләрен балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру кысаларында яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламенты»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Регламентта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарының 1 пунктында күрсәтелгән яңа туган балалы гаиләләр категорияләрен балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучыларның хезмәттәшлек итү (алга таба – ведомствоара хезмәттәшлек) буенча гомуми кагыйдәләре билгеләнә.»;

1.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарының 1 пунктында күрсәтелгән яңа туган балалы гаиләләр категорияләрен балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә төзегән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма (алга таба – субсидия алучы).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин